| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 6 феврале № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне һәм Лениногорск муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау турында» 98 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль законның 7нче статьясы һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 13нче статьясы, Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 98нче номерлы «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 нчы статьяга түбәндәге эчтәлекле 6.4 пунктын өстәргә:

«6.4. Гражданин муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына, ә муниципаль хезмәткәр якын туганлык яисә туганлык (ата-анасы, хатыны, балалары, бертуган, сеңелләре, шулай ук бертуган,

сеңелләре, ата-аналары, балаларының балалары) булган очракта, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, әлеге муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре итеп билгеләнә алмый.».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен конрольдә тотуны Лениногорск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Н. Г.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов